Хосусый гомуми белем бирү оешмасы
“№ 23 “Менеджер” урта мәктәбе”

“КАРАЛГАН”
№ 1 протокол
Кафедра җитәкчесе
\ Мотыйгуллина Э.А
кафедра утырышында
“17” 08. 2016 ел

“РАСЛАНГАН”
19.08.2016 № 1
педагогик совет тарафыннан
1.09.2016 № 8
мәктәп боерыгы белән кертелгән
Мәктәп директоры_____Е. Н. Резаева

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН
эш программасы

8 нче сыйныф, база дәрәҗәсе

Төзеде:
югары квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Хайруллина Әлфия Камил кызы

Әлмәт шәһәре, 2016 нчы ел.

Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

- Россия Федерациясенең “Мәгариф турында” федераль законы (Федеральным законом от 29 декабря 2012 г. № 273 “ Об образовании в Российской Федерации”

- Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” законы. (22 июнь 2013 ел №68)

- Татарстан Республикасының “Дәүләт телләре һәм Татарстан республикасында башка телләр” турындагы законы; (8.07.1992 . N 1560 – XII (3.03.2012 елгы редакциядә)

- Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту үрнәк программасы (Р.З.Хәйдарова,Р.Л.Малафеева, 1-11 нче сыйныфлар, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011)

- Хосусый гомуми белем бирү оешмасы “№ 23 “Менеджер” урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2014/19 уку елына төп гомуми белем бирүнең төп белем бирү программасына. (Основной образовательной программой основного общего образования Частного общеобразовательного учреждения “Средняя школа № 23 “Менеджер” на 2014 – 2019 учебный год.)

- Хосусый гомуми белем бирү оешмасы “№ 23 “Менеджер” урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2016/17 уку елының укыту планына
(Учебным планом ЧОУ “Средняя школа №23 “Менеджер” на 2016 – 2017 учебный год.)

- Положением о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) в ЧОУ “Общеобразовательная средняя школа №23 “Менеджер” (Хосусый гоомуми белем бирү оешмасы “№ 23 “Менеджер” урта мәктәбе” укытучысының эш программасы турында нигезләмәсе)

УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА

Рус телле балаларга татар теле укытуның төп максатлары

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы - иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле укыту максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

1. Танып белү максатының эчтәлеге

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Урта звенода Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстан символикасы, башкалабыз Казанның тарихы, бүгенге йөзе, Татарстанның территориясе, географик урыны, экономик бәйләнешләре, татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча билгеле булган шәхесләр, Бөек Җиңүгә Татарстанның өлеше турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куелды.

2. Үстерү максатының эчтәлеге

Белем бирү максаты методика фәнендә бик озак еллар буе беренчел дәрәҗәдәге максат итеп саналды. Ләкин дидактик максатларның башкаларын икенчел дәрәҗәдә дип карау, киресенчә, белем бирү максатының тиешле дәрәҗәдә тормышка ашырылмавына китерде. Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты (Л.С.Выготский). Бу хакыйкатьне балаларның белем алу эшчәнлегенең барлык этапларында да истә тоту зарур.

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дидуктив фикерләү;
- хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне устерү.

Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда бу максатлар беренче планга куела.

3. Тәрбияви максатның эчтәлеге

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Әлбәттә, укытучының шәхси сыйфатлары, укучы белән махсус оештырылган мөгамәләсе укыту-тәрбия процессында зур роль уйный. Ләкин, тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу - авторларның беренчел бурычы булды. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән, аларны кызыксындырган мораль проблемаларны үз эченә алган эчтәлек, беренчедән, укыту процессында тәрбияви функция башкарса, икенчедән, турыдан-туры коммуникатив мотивация туу белән бәйле.

Уку эшчәнлеген мотивлаштыру юнәлешендә эшләүче галим А.К.Маркова фикеренчә, эчтәлегендә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый. Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырылды һәм сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары тәкъдим ителде. Программаның **ачык характерда** булырга тиешлеген исәпкә алып, әдәби әсәрләр үзләре күрсәтелмәде, ә авторларны санап чыгу белән чикләнде.

Укучыларның кабул итү мөмкинлекләрен исәпкә алып, аралашу-сөйләшү проблемаларына туры килгән әдәби әсәрләрдән төрле өзекләр сайлауны дәреслек авторларына калдыру - методика фәнендә программага эчтәлек сайлауда монополиялектән котылуның бер юлы дип күрсәтелә.

4. Белем бирү максатының эчтәлеге

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Рус телендә сөйләшүче 8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбияты укытуның төп максаты:

укучыларны татарча аралашырга өйрәтү

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

- татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
- диалогик-монологик сөйләм телен камилләштерү;
- -программаның эчтәлегендә каралган коммуникатив бурычларны үтәүгә ирешү;
- Каюм Насыйри турында белемнәрен тирәнәйтү;
- татар халкының мәдәнияты белән таныштыруны дәвам итү;
- татар халкының матур әдәбият әсәрләре аша шәфкатьлелек, дуслык, белемгә омтылыш, ихтыр көче, эшчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү;
- татар халкының тарихы (болгарлар, Сөембикә), күренекле әдипләре белән таныштыру;
- татар халык авыз иҗаты – риваятьләр, легендалар турында белешмә бирү;

Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Хосусый гомуми белем бирү оешмасы "№ 23 "Менеджер" урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең укыту планында 8 сыйныфта татар әдәбияты дәресе атнага 2 сәгать исәбеннән каралган, шунлыктан программа 70 сәгатькә исәпләнгән.

Предмет нәтиҗәләрен контрольгә алу телдән сорау, яттан шигырь сөйләү, тыңлап аңлау , диалог - монологлар төзү, ситуатив күнегүләр эшләү , эчтәлек сөйләү, сочинение язу, контроль эшләр формасы һәм төрләре аша үткәрелә.

(Кушымта 1 – контроль эшләрнең графигы)

Арадаш аттестация нәтиҗәсе булып фән буенча үткәрелгән агымдагы барлык контроль эшләрнең уртача баллы санала.

(Кушымта 2 – контроль үлчәү материаллары)

Эшләрне бәяләү программа авторларының бәяләү нормаларына, Хосусый гомуми белем бирү оешмасы "№ 23 "Менеджер" урта гомуми белем бирү мәктәбе" укучыларының белем алу нәтиҗәләрен бәяләү системасы турындагы нигезләмәгә, 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре" методик тәкъдимнәренә таянып үткәрелә.

(Кушымта №3)

Тикшерү төрләре

№	**Эш төре**	
1	Тыңлап аңлау	1,2 минут
2	Диалогик сөйләм	9-10 реплика
3	Монологик сөйләм	10-12 фраза
4	Ситуатив күнегүләр	4
5	Сочинение язу	9-10 җөмлә

Сочинение темалары:

1.Китап – киңәшчем, дустым минем.
2.Дуслар белән күңелле.
3.Файдалы һәм файдасыз буш вакыт.
4.Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы

Эш программасының эчтәлеге (70 сәг.)

Бүлек исеме, сәгать саны	**Темалар**	**Сүзләр һәм сүзтезмәләр**
Күп укыган күп белер (12 сәг.)	Яхшы уку җиңелме? Яхшы уку һәм яхшы яшәү. Интернет аша үз белемеңне күтәрү. Татарстанның Милли китапханәсе.	Өлгерә, соңга кала, җитешә, иртәрәк, арый, сүз бирә, сүзендә тора, оныта, вакытында, борчыла, тантаналы, узды, бүлек, ялгышты, хәзинә, компьютерлаштырылган, аралаша, килешү, аңлатмалы сүзлек, мәдрәсә, фарсы, гарәп, эзли, эзи, аралашу, чит ил, килешү, сирәк басма, атаклы.
Мин һәм минем яшьтәшләрем (22 сәг.)	Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре. Дуслашу серләре. Нинди кызлар һәм малайлар ошый? Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтендә алдашу, ялганлашу кебек күренешләр. Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы, гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары. Укучылар арасындагы яшь талантлар.	аралашу, ялганлашу, һичшиксез, кызара, хата тану, читләшә, гаеп эзли, ялгышын тану, үпкәләшү, мөнәсәбәт, ялгыз, дәрәҗә, иркен, сөйкемле, тыйнак, ягымлы, сыра, тәмәке, батыр, горур, үзүзеннән артык канәгать, ант итү, кызыксыну, адым, терелә, көнозын, гарьләнү, елак, көнләшү, чая, кызыксыну, серле, төп роль, хезмәт бригадасы, яшелләндерү, чистарту, хезмәт хакы, гаилә бюджеты, үз өлешем.
Буш вакытымны мин ничек үткәрәм? (12 сәг)	“Егетлек". Яраткан музыка. Виртуаль аралашу ысуллары.	Тәртипсезлек, көчлелек, өлгерлек, егетлек, тупаслык, эшсезлек, башкаручы, иң, әйләнә-тирә, уртак тел табу, эчке дөнья, уен-көлке, игътибар үзәге, читләшү.
Табигать һәм кеше (7 сәг.)	Табигатькә сак караш. Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр. “Яшел планета” конкурсында, Мин чисталык яратам”, “Кошларга ярдәм” акцияләрендә катнашу турында.	көрәшү, ягулык, учак ягу, чүпчар, пычрату, чишмә, Җир шары, дым саклау, катнаша, җиңә.
Без Татарстанда яшибез (5 сәг.)	Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары. Казан шәһәрендәге яңа үзгәрешләр. Казанның бүгенге йөзе,	Европа, көнчыгыш, чикләшә, мәйдан, төньяк, көньяк, күмер, бакыр, балчык, бүгенге йөзе, кайсы, оештырыла, истәлек, корылмалары.

	архитектура истәлекләре, яңа ял итү урыннары.	
Татарстанның күренекле әдипләре (10 сәг.)	Габдулла Тукай, Муса Җәлил Абдулла Алиш. А.Алиш, Галимҗан Ибраһимов.	Мәдрәсә, ятим, үги әби, иҗат итә, ачы язмыш, яланаяк, асрарга, олаучы, гаҗәпләнде, кала, күрше авыл, мәкалә, әдәби әсәр, Бөек Ватан сугышы, әсирлек, тоткынлык, көрәш, төрмә, фашизмга каршы, легионерлар, үлемсез, мәңгелек, дан.
Кабатлау – 2 сәг.		

6 – 9 нчы сыйныф укучылыры өйрәнергә тиешле әсәр авторлары исемлеге

6нчы сыйныф	**7нче сыйныф**	**8нче сыйныф**	**9нчы сыйныф**
Ф.Яруллин	Һ.Такташ	Дәрдемәнд	С.Хәким
Т.Миңнуллин	М.Мәһдиев	Г.Тукай	Г.Әпсәләмов
Ш.Галиев	Р.Миңнуллин	Ф.Яруллин	Г.Ахунов
Р.Вәлиева	Ш.Галиев	В.Нуриев	И.Гази
М.Җәлил	Л.Лерон	Ф.Шәфигуллин	М.Мәһдиев
	Р.Вәлиев	М.Галиев	Ф.Яруллин
		Л.Лерон	Р.Миңнуллин
		Р.Вәлиева	Ш.Галиев
		Н.Гыйматдинова	Р.Вәлиев
			Р.Вәлиева

<u>Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр:</u>

1.Ш.Галиев. Безнең йорт малайлары (ошаган ике строфаны).

2.Н.Дәүли. Бәхет кайда була?

Календарь-тематик план

Календарь- тематик планда дәрес типларының исемнәре кыскартылып күрсәтелде:

ЛКФ- лексик күнекмәләр формалаштыру
ЛКК-лексик күнекмәләрне камилләштерү
ГКФ-грамматик күнекмәләр формлаштыру
ГКК-грамматик күнекмәләрне камилләштерү
ЛГКК-лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү
Д/МС-диалогик/монологик сөйләм дәресләре

№	Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы	сәг саны	Дәрес тибы	Эчтәлек элементлары	Укучылар эшчәнлеге	Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр	Контроль эш төре	дата	
								план	факт
	I.Күп укыган - күп белер (12 сәг.)								
1.	*Эш урынында иминлекне саклау кагыйдәләре.* **Р.Вәлиева.** Мәктәбем.	1	ЛКФ	Р.Вәлиеваның “Мәктәбем” шигыре белән танышу.	Шигырьне укырга, диалоглар төзеп сөйләшергә, ситуатив күнегүләр эшләргә	Эчтәлеген аңлау “мәктәп” темасына кагылышлы лексиканы иркен куллану	агымдагы	2.09	
2.	Каюм Насыйриның биографиясе.	1	ЛКК	Каюм Насыйриның биографиясе белән танышу.	Биография буенча план төзергә, планга нигезләнеп, эчтәлеген сөйләргә	Бөек шәхеснең күпкырлы эшчәнлеген истә калдыру һәм сөйли белү	агымдагы	2.09	
3.	К. Насыйриның “Әбүгалисина” әсәренең 1нче өлеше	1	ЛКК	әсәренең 1нче өлешен уку. Изгелек, эти-әнигә мәрхәмәт төшенчәләрен ачу.	Сорауларга җавап бирергә, эчтәлеген сөйләргә	Эчтәлеген аңлау һәм ситуатив күнегүләрдә куллана белү.	агымдагы	9.09	

4	К.Насыйриның “Әбүгалисина” әсәренең 2нче өлеше.	1	ЛКК	Әсәрнең икенче өлеше белән танышу	Ситуатив күнегүләр эшләргә	Эчтәлеген аңлау. Белемле булу җиңел эш түгел, фикерен ача белү. “Белемле кеше югалмас” мәкален ачу, тормыштан мисаллар китерә белү.	агымдагы	9.09	
5	**В.Нуриев**.Өлгерәм әле. 1нче өлеш.	1	ЛКК	әсәренең 1нче өлешен уку.	Җөмләләрне хикәя тәртибендә урнаштырырга, малайның теләген белдерергә, эчтәлеген сөйләргә	Эчтәлеген сөйли белү.. Үзгәртеп язу һәм сөйләү. Диалоглар буенча сөйләшә белү.	агымдагы	16.09	
6	В.Нуриев.Өлгерәм әле. 2нче өлеш.	1	ЛКК	әсәренең 2нче өлешен уку.	Сорауларга җавап бирергә, тиешле репликалар куеп язарга, ситуатив күнегүләр эшләргә.	Яхшы уку өчен киңәшләр бирә белү, хикәяне үзгәртеп сөйли белү.	агымдагы	16.09	
7	**Яхшы уку җиңелме?**	1	д/мс	**“яхшы уку җиңелме?” проблемасы буенча сөйләшү.Үзең алдында куелган таләпләрне әйтә белү.Яхшы яшәү өчен яхшы уку кирәкме? соравына җавап эзләү.**	Бирелгән темалар буенча фикер алышырга	**“яхшы уку җиңелме?” темасы буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыга белү. Яхшы яшәү өчен яхшы уку кирәкме? дигән сорауга җавап бирү.**	агымдагы	23.09	
8	**Р.Вәлиева.**Барый телевизор карый.	1	ЛКФ	Р.Вәлиеваның шигыре белән танышу. Уртаклык төшенчәсен ачу.	Шигырьне сәнгатьле укырга, киңәшләр язарга	Шигырьне сәнгатьле уку. Барый белән хикәя герое арасындагы уртаклыкны таба белү. Малайларга киңәш бирә белү.	агымдагы	23.09	

9	**Татарстанның Милли китапханәсе**	1	ЛКФ	Татарстанның Милли китапханәсе турында уку	Ситуатив күнегүләр эшләргә, диалоглар төзергә, сүзлекләр белән эшләргә	**Татарстанның Милли китапханәсе турында сөйли белү.** Диалогик-монологик сөйләмгә чыгу.	агымдагы	30.09	
10	**Ләбиб Лерон.** Пирамида.	1	ЛКК	Әсәр эчтәлеген үзләштерү	Укып тәрҗемә итергә, сүзлекләр белән эшләргә	Эчтәлеген сөйли белү, ситуатив күнегүләрдә ача белү.	агымдагы	30.09	
11	**Сочинение №1. Китап – киңәшчем, дустым минем.**	1	ЛКК	**“Мин һәм интернет” темасына, Интернет аша үз белемеңне күтәрү турында сөйләшү**	Сүзлекләр белән эшләргә, сочинение язарга	Интернет – белем күтәрү чыганагы булуын җиткерә белү. Китап- киңәшче, дус булуы турында эзлекле яза белү	агымдагы	7.10	
12	**“Күп укыган - күп белер” бүлеге буенча контроль эш**	1	д/мс	Бүлек буенча өйрәнгән материалны кабатлау	Биремле карточкалар белән эшләргә	“Күп укыган - күп белер” бүлеге буенча алган белем-күнекмәләрне куллана белү	**Контроль эш №1**	7.10	
	II. Мин һәм минем яшьтәшләрем (22 сәг.)								
13	**Н.Гыйматдинованың** тормыш юлы.	1	ЛКФ	Н.Гыйматдинованың тормыш юлы.	Сүзлекләр белән эшләргә, сорауларга җавап бирергә, ситуатив күнегүләр эшләргә	Язучының тормыш юлы турында белешмә бирә белү.	агымдагы	14.10	
14	Н.Гыйматдинова. Болын патшасы. 1нче бүлек.	1	ЛКФ	“Болын патшасы” хикәясенең 1нче бүлеге белән танышу	Сүзлекләр белән эшләргә, тәрҗемә эше	Сораулар аша эчтәлеген сөйли белү.	агымдагы	14.10	
15	Н.Гыйматдинова.Болын патшасы. 2нче бүлек.	1	ЛКК	“Болын патшасы” хикәясенең 2нче бүлеге белән танышу.	Сүзлекләр белән эшләргә, сорауларга җавап бирергә, ситуатив күнегүләр эшләргә.	1-2 бүлекләр буенча диалоглар төзеп сөйли белү.	агымдагы	21.10	

16	“Болын патшасы” хикәясенең 1-2 бүлекләре буенча диалоги-монологик сөйләм.	1	д/мс	“Болын патшасы” хикәясенең 1-2 бүлекләре буенча диалоги-монологик сөйләмгә чыгу	Диалог-монологлар төзергә	Диалогик-монологик сөйләмгә чыга белү	агымдагы	21.10	
17	Н.Гыйматдинова. Болын патшасы. 3нче бүлек.	1	ЛКК	Н.Гыйматдинованың “Болын патшасы”хикәясенең 3нче бүлеген аңлап уку	Эчтәлеген сөйләргә, биремнәр эшләргә.	Хикәяне сүзлексез аңлап уку. Айсылуның мәрхәмәтле кыз булуын раслый белү	агымдагы	28.10	
18	Н.Гыйматдинова.Болын патшасы. 4 нче бүлек.	1	ЛКК	Н.Гыйматдинованың “Болын патшасы”хикәясенең 3- 5 нче бүлекләрен укып әңгәмә кору.	Дәреслектәге биремнәрне эшләргә, диалоглар төзеп сөйләшергә	**Яшьтәшләреңбелән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре турында сөйли белү.**	агымдагы	28.10	
19	Н.Гыйматдинова.Болын патшасы. 5 нче бүлек.	1	ЛКК	**Яшьтәшләреңбелән аралашу кагыйдәләре турында сөйләшү.**	Биремле карточкалар буенча эшләргә.	Ситуатив күнегүләрне эшли белү. Әсәрне дәвам итеп яза алу.	агымдагы	11.11	
20	“Болын патшасы” хикәясенең 3-5 бүлекләре буенча диалоги-монологик сөйләм.	1	д/мс	**дуслашу серләре турында сөйләшү.**	Диалог-монологлар төзергә.	Диалогик-монологик сөйләмгә чыга белү.	агымдагы	11.11	
21	**Миңа нинди кызлар һәм малайлар ошый?**	1	д/мс	**нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү**	Сүзлекләр белән эшләргә, таблица буенча эшләргә. Хикәя язарга.	нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында аңлата белү. Кешенең уңай холык сыйфатларын күрергә өйрәтүКешенең уңай холык сыйфатларын күрсәтә белү.	агымдагы	18.11	
22	Ш.Галиевның биографиясе.	1	ЛКК	Ш.Галиевның биографиясе белән танышу.	Сүзлекләр белән эшләргә, хронологик таблица төзергә	Биографиясен сөйли белү.	агымдагы	18.11	

23	Ш.Галиев.Безнең йорт малайлары.	1	ЛКК	Шигырь эчтәлеге белән танышу	Сүзлекләр белән эшләргә, фикер алышырга, сәнгатьле укырга	Шигырьне сәнгатьле уку.Сораулар буенча эчтәлеген сөйләү.	агымдагы	25.11	
24	К.Даянның “Өзелгән чәчәкләр” хикәясенең 1нче өлеше.	1	ЛКК	Әсәр эчтәлеген 1 нче өлешен үзләштерү.	Сүзлекләр белән эшләргә,сорауларга җавап бирергә, эчтәлеген сөйләргә	Яхшы бала әнисенә хәсрәт китерми фикерен аңлау	агымдагы	25.11	
25	К.Даянның “Өзелгән чәчәкләр” хикәясенең 2нче өлеше.	1	ЛКК	“Яхшы бала әнисенә хәсрәт китерми” фикерен ачу.	Диалогларны рольләргә бүлеп укырга, план төзергә, төркемнәрдә эшләргә.	Хикәяне аңлап уку. Әхмәткә бәя бирә белү.	агымдагы	2.12	
26	К.Даянның “Өзелгән чәчәкләр” әсәре буенча диалогик-монологик сөйләм	1	д/мс	Өлкәннәргә, аларның хезмәтенә хөрмәтле караш тәрбияләү. К.Даянның “Өзелгән чәчәкләр” әсәре буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу.	Диалог-монологлар төзергә	Диалогик-монологик сөйләмгә чыга белү	агымдагы	2.12	
27	**М.Галиев.** Җиңәсем килде.	1	ЛКК	Әсәр эчтәлеге белән танышу	Сүзлекләр белән эшләргә, рольләргә бүлеп укырга	Төп геройның эчке кичерешләрен дөрес бәяләү.	агымдагы	9.12	
28	М.Галиев. Җиңәсем килде.	1	ЛГКК	**Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтендә алдашу, ялганлашу кебек күренешләргә караш белдерә белү.**	геройга бәя бирергә, эчтәлеген сөйләргә.	Илгизгә бәя бирү.**Ялганлашу – начар гадәт булуын аңлау. “Җиңү ялганга нигезләнергә тиеш түгел” фикерен аңлау.**	агымдагы	9.12	
29	М.Галиевның “Җиңәсем килде” әсәре буенча диалогик-монологик сөйләм.	1	д/мс	М.Галиевның “Җиңәсем килде”әсәре буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу.	Диалог-монологлар төзергә	Диалогик-монологик сөйләмгә чыга белү	агымдагы	16.12	

30	Абдулла Алиш биографиясе	1	ЛКФ	Абдулла Алишның биографиясен өйрәнү	Сүзлекләр белән эшләргә, биографиясен сөйләргә, хронологик таблица төзергә	Биографиясен аңлап уку, сөйли белү	агымдагы	16.12	
31	А.Алиш. Алдакчы Наил.	1	ЛКК	Текстның эчтәлеген үзләштерү.	Текстны укырга, тәрҗемә итергә	Эчтәлеге буенча үз фикерләрен белдерә белү	агымдагы	23.12	
32	.Алиш. Алдакчы Наил.	1	ЛКК	**Алдашу, ялганлашу – начар гадәт, дигән фикергә килү.**	Диалоглар төзергә, төркемнәрдә эшләргә, ситуатив күнегүләр эшләргә.	**Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтендә ялганлашу, алдашу кебек күренешләргә үз фикерләрен белдерә белү.**	агымдагы	23.12	
33	**Сочинение №2. Дуслар белән күңелле.**	1	б.с.ү.	Бәйләнешле сөйләм телен үстерү	Эзлекле итеп монолог язарга	**Дуслар белән вакытны үткәрү күңелле булуын ача алу**	**Сочинение №2.**	14.01	
34	**“Мин һәм минем яшьтәшләрем” бүлеге буенча контроль эш.**	1	ЛГГ	Бүлек материалын искә төшерү.	Биремле карточкалар буенча эшләргә	“Мин һәм минем яшьтәшләрем” бүлегендә алган белем-күнекмәләрне куллана белү.	**контроль эш №2**	14.01	
	Буш вакытны мин ничек үткәрәм? (12 сәг.)								
35	Ш.Галиев. Ялгыш адым.	1	ЛКФ	Ш.Галиевның “Ялгыш адым” шигыре белән танышу.**“Егетлек” проблемасы буенча сөйләшү.**	Таблица буенча эшләргә, биремле картлчкалар буенча эшләргә	**“Егетлек” проблемасы буенча диалогка керә белү**	агымдагы	21.01	
36	Буш вакыт.	1	ЛКФ	“Буш вакыт – ул нинди вакыт?” темасына сөйләшү. **Виртуаль аралашуның төрле ысуллары турында сөйләшү.**	Монологлар төзеп сөйләшергә	Файдалы һәм файдасыз үткән вакыт ничек аерыла? дигән фикерне аңлата белү. Буш вакыт турында сөйли белү **Виртуаль аралашуның төрле**	агымдагы	21.01	

						ысуллары турында сөйли белү			
37	**Ф.Шәфигуллинның** биографиясе.	1	ЛКФ	Ф.Шәфигуллинның биографиясе белән танышу.	Сүзлекләр белән эшләргә, хронологик таблица төзергә	Кешенең тышкы кыяфәтен сурәтли белү.	агымдагы	28.01	
38	Ф.Шәфигуллинның Әнфисә кемгә елмая?	1	ЛКК	Әсәрнең эчтәлеген үзләштерү.	Сүзлекләр белән эшләргә, текстны өлешләргә бүләргә, исем бирергә	Эчтәлеге буенча сөйләмгә чыга белү	агымдагы	28.01	
39	Ф.Шәфигуллинның Әнфисә кемгә елмая?	1	д/мс	**Яраткан музыкаң буенча фикер алышу. Укучылар арасында яшь талантлар**	эчтәлеген сөйләргә, ситуатив күнегүләр эшләргә, фикер алышырга	**Укучылар арасында яшь талантлар турында әйтә белү** Яраткан музыкаң яисә төркемең турында сөйли белү	агымдагы	4.02	
40	Р.Миңнуллин. Подъезддагы язулар.	1	ЛКК	Р.Миңнуллинның “Подъезддагы язулар” шигырен сәнгатьле уку	Сүзлекләр белән эшләргә, диалоглар төзеп сөйләшергә, хикәя язарга	Кушаматлар турында сөйләшү, стена бозуның начарлыгын аңлау	агымдагы	4.02	
41	Безнең йортның подъезды.	1	д/мс	Әхдлакый кыйммәтләр тәрбияләү.	Сүзлекләр белән эшләргә, монолог төзергә	“Безнең йортның подъезды” темасы буенча фикер алышу	агымдагы	11.02	
42	**Ф.Яруллинның биографиясе**	1	ЛКФ	Ф.Яруллинның биографиясе белән таныштыру	Хронологик таблица төзергә, диалоглар төзеп сөйләшергә, биографиясен сөйләргә	Ф.Яруллинның биографиясен сөйли белү..	агымдагы	11.02	
43	Ф.Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала” әсәре.	1	ЛКК	Әсәрнең эчтәлеген үзләштерү	Сүзлекләр белән эшләргә, табышмакларга җавап бирергә, кроссворд чишәргә	Фәниярнең көчле булып үсү сәбәпләрен аңлата белү.	агымдагы	18.02	

44	Ф.Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала” әсәре.	1	д/мс	Әсәр эчтәлеге буенча диалогик- монологик сөйләмгә чыгу.	Тәрҗемә итәргә, дәреслектәге күнегүләрне эшләргә, биремле карточкалар буенча эшләргә	Фәнияр турында сөйли белү	агымдагы	18.02	
45	**Сочинение №3. Файдалы һәм файдасыз буш вакыт.**	1	ЛКК	Файдалы һәм файдасыз буш вакыт турында сөйләшү	План буенча сөйләргә, мәкальләрне тәрҗемә итәргә, фикер алышырга	Сораулар буенча буш вакыт турында сөйли һәм яза белү	**Сочинение №3**	25.02	
46	**“Буш вакытны мин ничек үткәрәм? бүлеге буенча контроль эш.**	1	ЛКК	Бүлек материалын гомумиләштереп кабатлау	Биремле карточкалар буенча эшләргә	“Буш вакытны мин ничек үткәрәм? темасы буенча алган белем-күнекмәләрне куллана белү	**контроль эш №3**	25.02	
	Табигать һәм кеше (7 сәг.)								
47	Нәби Дәүли биографиясе	1	ЛКФ	Н.Дәүлинең биографиясе белән танышу	Хронологик таблица төзергә, биографиясен сөйләргә	Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү.	агымдагы	11.03	
48	Н.Дәүли. Бәхет кайда була?	1	ЛКК	Шигырь эчтәлеген үзләштерү: агач җимеше белән –кеше эше белән. **Табигатькә сак караш турында сөйләшү**	Сорауларга җавап бирергә, мәкальләрнең мәгънәләрен ачарга, ятларга, ситуатив күнегүләр эшләргә	Шигырьне сәнгатьле уку. Диалоглар төзеп сөйли белү. Мәкальләрнең мәгънәсен аңлата алу.	агымдагы	11.03	

49	1)Н.Дәүлинең “Хезмәткә - хөрмәт” .	1	ЛКФ	Хикәя эчтәлеген үзләштерү. **Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү. Чишмәләр- изге урын, ял итү урыны, шуңа күрә... .**	Сүзлекләр белән эшләргә, киңәшләр язарга, диалолар буенча сөйләшергә	Ташланган икмәк кә, төрле чүп-чарга битараф булмаска өйрәтү.	агымдагы	18.03	
50	1)**Дәрдемәндның** биографиясе.	1	ЛКФ	Дәрдемәндның биографиясе белән танышу.	Сүзлекләр белән эшләргә, план төзергә, диалоглар буенча сөйләшергә, эчтәдеген сөйләргә	Хикәянең төп эчтәлеген аңлауга ирешү. Эчтәлеген сөйли белү.	агымдагы	18.03	
51	Дәрдемәнд.Бер хәзинә.	1	д/мс	**Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы,гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары турында сөйләшү.**	Сүзлекләр белән эшләргә, монологлер төзеп сөйләргә	Һөнәр ияләренә кагылышлы лексиканы урынлы куллану. **Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы,гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары турында сөйли белү.**	агымдагы	25.03	
52	**Сочинение №4.Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы.**	1	д/мс	Р.Миңнуллин. Кирәк! Шигырь эчтәлеген үзләштерү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү	Сүзлекләр белән эшләргә, план төзергә, монолог язарга	Табигатьне саклау – һәркемнең изге бурычы турында яза белү	**Сочинение №4.**	25.03	

53	**“Табигать һәм кеше” бүлеге буенча контроль эш.**	1	д/мс	**“Мин чисталык яратам”, “Кошларга ярдәм” акцияләрендә катнашу турында сөйләшү. Оксана “Яшел планета” конкурсында беренче урынны алды, чөнки ул ... .**	Биремле карточкалар буенча эшләргә	“Табигать һәм кеше” бүлеге буенча алган белем-күнекмәләрне куллана белү.	**контроль эш №4**	1.04	
	Без Татарстанда яшибез (5 сәг.)								
54	Р.Фәйзуллин. Онытма син!	1	ЛКФ	Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары	Карта буенча күзәтергә, диалог-монологлар төзеп сөйләшергә	Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары турында сөйли белү	агымдагы	1.04	
55	Р.Фәхретдинов. Идел суы ага торыр...	1	ЛКК	Казан шәһәре турында	Өстәмә чыганаклар файдаланырга, монолог төзеп сөйләргә	Казан шәһәре турында мәгълүмат бирә белү	агымдагы	8.04	
56	Сөембикә манарасы.	1	ЛКК	**Казан шәһәрендәге үзгәрешләр турында сөйли белү. Татарстан Европаның көнчыгышында урнашкан.**	Өстәмә чыганаклар буенча чыгыш ясарга	**Казан шәһәрендәге яңа үзгәрешләр, яңа ял итү урыннары турында сөйли белү**	агымдагы	8.04	
57	Туган җирем - Татарстан	1	ЛКК	**Татарстанның урыны климаты, мәйданы, табигый байлыклары турында сөйли белү. Миңа Казан метросы ошады. Казанда яңа спорт корылмалары төзелде.**	Презентацияләр буенча чыгыш ясарга	Архитектура истәлекләре турында белешмә бирә белү	агымдагы	15.04	

58	Татарстанның Милли музеенда	1	д/мс	**Бүгенге Казан, архитектура истәлекләре, яңа ял итү урыннары. Сиңа Бауман һәм Санк – Петербург урамнарының кайсы күбрәк ошый? Без аквапаркта ял итәргә яратабыз, чөнки ... .**	Сүзлекләр белән эшләргә, диалог-монологлар төзеп сөйләшергә	Тема буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыга алу	агымдагы	15.04	
	Татарстанның күренекле әдипләре (10 сәг.)								
59	**Г.Тукайның** биографиясе.	1	ГКФ	Г.Тукайның биографиясе белән танышу	Хронологик таблица төзергә, дәреслектәге күнегүләрне эшләргә	**Г.Тукай турында сөйли белү**	агымдагы	22.04	
60	Г.Тукайның “Исемдә калганнар.”	1	ЛКК	Автобиографик әсәр төшенчәсен ачу.Эчтәлеген үзләштерү.	Сүзлекләр белән эшләргә, хикәяне укып тәржемә итәргә	Шагыйрьнең балачагыннан эпизодлар белән танышу һәм сөйли белү.	агымдагы	22.04	
61	Г.Тукайның “Исемдә калганнар”	1	ЛКК	әсәр эчтәлеге аша диалогик-монологик сөйләмгә чыгу	диалоглар төзергә, таблица буенча эшләргә, монолог язарга, тест эшләргә	Диалоглар төзеп сөйли белү	агымдагы	29.04	
62	1)Ә. Фәйзинең “Асрарга бала бирәм” әсәреннән өзек.	1	ЛКФ	Әсәрнең эчтәлеген үзләштерү, фикер алышу.	Сүзлекләр белән эшләргә, тәржемә итәргә	Тукайның тормыш юлы белән танышуны дәвам итү.	агымдагы	29.04	
63	Ә. Фәйзинең “Асрарга бала бирәм” әсәреннән өзек.	1	ЛКК	Әсәр эчтәлеге аша диалогик-монологик сөйләмгә чыгу	текстны өлешләргә бүләргә, исем бирергә, хронологик таблица төзергә, ситуатив күнегүләр эшләргә	Г.Тукайның ни өчен тормышы кыска булган соравы буенча фикерләрен әйтә белү	агымдагы	6.05	

64	Г.Тукайның “Су анасы”.	1	ГКФ	“Су анасы” шигырен уку, “кеше әйберенә тиргә ярамый!” дигән фикергә килү.	Сүзлекләр белән эшләргә, сәнгатьле укырга	Поэманың төп идеясен ачу.	агымдагы	6.05	
65	“Нәни батыр”	1	ЛКК	С.Алишевнең “Нәни батыр” хикәясен тәрҗемә итеп уку.	Сүзлекләр белән эшләргә, хикәяне тәрҗемә итәргә., диалоглар төзеп сөйләшергә	**Абдулла Алиш – Җәлилнең иптәше булуы турында сөйли белү.** **Муса Җәлил турында сөйли белү. Советлар Союзы герое исеменә лаек булуын әйтә белү.**	агымдагы	13.05	
66	**Йомгаклау контроль эше**	1	Контроль	Алган белемнәрне тормышта куллана белү	Орфографик сүзлекләр белән эшләргә	Алган белемнәрне куллана белү		13.05	
67	**Г.Ибраһимовның биографиясе .**	1	ГКФ	Г.Ибраһимовның биографиясе белән танышу.	Хронологик таблица төзергә, сорауларга җавап бирергә	**Галимҗан Ибраһимов турында белешмә бирә белү.**	агымдагы	20.05	
68	Г.Ибраһимов. “Алмачуар” әсәре.	1	ЛКК	Әсәр эчтәлеген үзләштерү, татар халкының милли бәйрәме турында сөйләшү.	Текстны тәрҗемә итәргә, дәреслектәге күнегүләрне эшләргә, эчтәлеген сөйләргә, биремле карточкалар буенча эшләргә	**“Алмачуар” әсәренең эчтәлеген сөйли белү**	агымдагы	20.05	
	Кабатлау (2 сәг.)								
69	Кабатлау. Лексика.	1	ЛКК	Ел буе өйрәнгән лексиканы кабатлау, истә калдыру дәрәҗәсен тикшерү	Сүзләрне тәрҗемә итергә	Сүзләрнең тәрҗемәсен белү	агымдагы	27.05	
70	Йомгаклау дәресе.	1	ЛКК	Уку елына йомгак ясау	Бәйгедә катнашырга	Өйрәнгән белемнәрне куллана белү	агымдагы	27.05	

8 сыйныф укучылары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр

1. Укылган әсәрләрдән төп фикерне укучының аерып күрсәтә алуы, үз сүзләре белән төп фикерне әйтә белүе, текстның төп фикерен билгеләп, өлешләргә, кисәкләргә аеру.
2. Текстны үзлектән төзелгән планга нигезләнеп, иллюстрациягә таянып, кыска һәм төгәл итеп сөйли белү.
3. Әдәби әсәрдәге геройларга бәя бирә белү.
4. диктор сөйләмен тыңлап, эчтәлеге буенча мөстәкыйль эшләр эшли алу.
5. әдәби әсәрләрдән алынган өзекләрне аңлап уку, кирәкле мәгълүматны табып әйтү.
6. шигырьләрне яттан өйрәнү

Коммуникатив максатларны үтәүгә куелган таләпләр:

“Яхшы уку җиңелме?” проблемасы буенча сөйләшүдә катнаша алу.
“Яхшы уку һәм яхшы яшәү” проблемасы буенча фикер алышу.
Интернет аша үз белемеңне күтәрү турында сөйли белү.
Татарстанның Милли китапханәсе турында сөйли белү.
Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйлли белү.
Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтендә алдашу, ялганлашу кебек күренешләргә үз карашын белдерә белү.
Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы, гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары турында әйтә белү.
Укучылар арасындагы яшь талантлар турында әйтә белү.
“Егетлек" проблемасы буенча сөйләшү.
Яраткан музыкаң буенча фикер алышу.
Виртуаль аралашуның төрле ысуллары турында сөйли белү.
Табигатькә сак караш турында әйтә белү.
Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү
“Яшел планета” конкурсында, Мин чисталык яратам”, “Кошларга ярдәм” акцияләрендә катнашу турында әйтә белү.
Татарстанның урнашкан урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары турында сөйли белү.
Казан шәһәрендәге яңа үзгәрешләр турында сөйли белү.
Казанның бүгенге йөзе, архитектура истәлекләре, яңа ял итү урыннарын әйтә белү.
Габдулла Тукай, Муса Җәлил Абдулла Алиш турында сөйли белү. Аларның шигырьләрен яттан сөйләү.
А.Алиш, Галимҗан Ибраһимов турында белешмә бирә белү, әсәрләренең эчтәлеген кыскача сөйли алу.

Укыту-методик комплекты

1.Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту үрнәк программасы (Р.З.Хәйдарова,Р.Л.Малафеева, 1-11 нче сыйныфлар, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011)
2.Татар теле. 8 сыйныф.Р.З.Хәйдарова,Р.Л.Малафеева. Казан “Мәгариф” нәшрияты, 2008 ел

Өстәмә әдәбият

1.Гомуми урта белем бирү мәктәпләренең 8 нче сыйныфында укучы рус телле балаларга татар теленнән контроль эшләр. Р.З.Хәйдарова, Г.М. Әхмәтҗанова. Яр Чаллы, 2010

2 5-9 сыйныфларның рус төркемнәрендә укучы балаларның татар теленнән белемнәрен тикшерү өчен контроль биремнәр. Д.М.Гыйльманова. Яр Чаллы, 2008

3.Татар теленнән мөстәкыйль эшләр. З.Н.Хәбибуллина.Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2008 ел.

4.Гамәли татар теле (татар телен өйрәнүчеләр өчен методик кулланма). Р.Ф.Фаттахова. Казан, 2012

5.Татарский язык в таблицах. Р.З.Хайдарова, Р.Л.Малафеева. Яр Чаллы, 2005

6.Сборник правил по татарскому языку для русскоязычных учащихся. Р.С.Нурмухаметова, Казан, 2008

7.Сборник ситуативных упражнений по татарскому языку для русскоязычных учащихся. Р.З.Хайдарова, Л.А.Гиниятуллина. Яр Чаллы, 2004